

ISSN 0868-4545

Салават күпере





КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

Укучым!

Озакламый Казан шәһәренең төзелүенә 1 мең ел тулу бәйрәме килеп җитә.

1 мең ел – бик зур вакыйга. Чөнки Мәскәү кадәр Мәскәү дә моннан 850 ел элек кенә барлыкка килгән әле. Ә Казанга – мең яшь!

Шул уңайдан синең журналың «Әбиеңә дә сөйлә» дигән яңа сәхифә-рубрика ачып җибәрә. Ни өчен «Әбиеңә дә сөйлә»ме? Чөнки безне, ягъни татарларның һәм Казанның чын тарихын әле генә дөрес итеп сөйли башладылар. Моңарчы безнең халыкның тарихын гел алдап, ялганлап килделәр. Әби-бабайлар яшь вакытта бу бигрәктә шулай булган.

Хәзер безнең күзләр ачылды. Син үзең генә түгел, әби-бабайлар да дөреслекне белсен! Шуңа күрә сәхифәнең исемен «Әбиеңә дә сөйлә» дип куйдык.

Зиннур ХӨСНИЯР,
баш мөхәррир.

Без – татар балалары

Татар халкы Рәсәйдә сан буенча 2 нче урында тора.

Себер, Әстерхан татарлары да, керәшен татарлары һәм башкалар да шул бер үк татар халкы кешеләре. Алар һәммәсе бер милләт – татар милләте. Шартлы рәвештә татарлар төрле исемнәр белән аталып йөртелә. Чөнки бу зур җир шарында татар яшәмәгән урын юк.

Казан татарлары
Кырым татарлары
Себер татарлары
Литва татарлары
Әстерхан татарлары
Касим татарлары
Татар-мишәрләр
Керәшен татарлары

© "Салават күпере", 2002 ел



Шулай ук типтәр дип йөртелүче кешеләр дә безнең татарлар. Алар Башкортостанда һәм аның чиктәш районнарында яшиләр. Башкортостанның үзендә генә дә миллионлаган татар-типтәрләр яши. Чөнки бу җирләрнең күп өлеше элек татар җирләре булган.

Колагына киртләп куй:

Себер, Әстерхан, Касим, Кырым һәм башка татарлар шуңа өстәп мишәрләр, керәшеннәр, типтәрләр татар түгел дип «куык очыручылар», ягъни ялганлаучылар бар. Юк, алар барысы да бер халык – татарлар. Андый ялганчылар үзләренең бу әкиятләрен хәтта әбиләренә дә сөйләп маташмасыннар.

Татар белән татардан – татар баласы туган! Урыс белән марҗа малае – урыс була!.. Бүтәнчә сөйләп, кешеләрнең ялган белән башларын катыручылар әбиләренә бездән сәлам әйтсеннәр, яме!..



Рәссам Алла АЙСИНА



КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА

1552 нче елның 2 октябрендә Казан хан ханлыгы үзенең бәйсезлеген югалта.

Бу хәл моннан 450 ел элек була. Шартлы рәвештә һәм якынча кеше 80 яшькә чаклы яши дип уйласак:

– безнең 5 нче яки 6 нчы буын бабаларыбыз урысларга каршы сугышта батырларча һәлак булган.

– кеше үзенең 7 бабасын яхшы белергә тиеш!



Сорау:

Әлеге исәпләүләрдән чыгып, шуны бел: син җиде бабаңны беләсеңме? Рәхимсез сугышта синең ни исемле бабаң кан койган?

Укучым! Шул бабаңның исемен редакциягә язып җибәр. Мәнле, мәгънәле һәм акыллы балаларга «Салават күпере»нең бүләкләрен җибәрәчәкбез. Шуңа күрә төгәл адресыңны күрсәтергә онытма! Ә бүләк... бүләк бик шәп булачак безнең! Ипидер менә!..

Үз халкының бәйсезлеге өчен кан койган, фидакарь бабаларыбызга мәңгелек дан! Аларның урыннары мәңгелек җәннәттә булсын!

Җәннәт нәрсә соң ул дисеңме?

Җәннәт

Җәлил хәзрәт дәресләреннән

Җәннәт – ул хуш һәм күркәм урындыр, чөнки ул – тәкъва мөселманнарга ахирәт тереклегендә сөенечтә яшәсеннәр өчен билгеләнгән урын. Анда керүчеләр 33 яшьтә булалар, кайгы-хәсрәт, авыруны белмиләр, тәннәреннән бернинди дә нәҗес бүлеп чыгармыйлар, Аллаһның дидарын күрәләр һәм мәңге сәгадәттә булалар. Кайвакыт: «Анда фәлән буламы икән, анда төгән буламы икән?» – дип җирдәге төрле рәхәтләрне сорыйлар. Җәннәт – ул җирдә түгел, андагы рәхәтлекләрне җирдәгечә күзаллау аны чикләү булыр иде. Җәннәткә кереп, Аллаһның дидарын күргәч, кешеләр шулкадәр сөенеч-сәгадәткә ирешәчәкләр, башларында бернинди уй-хәсрәт калмаячак һәм бу рәхәтлек мәңге дәвам итәчәк, ул безнең җирдә кичерә торган рәхәтлекләребездән күп өстен, һәм ул безнең акыл кысаларына гына сыеп бетә торган түгел.



Рәссам Алла АЙСИНА

Зиннур ХӨСНИЯР

Алмачуар әкияте

Укучым! Бу санда әкиятнең дәвамын тәкъдим итәбез. Берничә җөмлә белән генә аның башында (ул журналның 8-9 саннарында) нинди хәлләр булганын сөйләп үтик:

Бик бәхетле илдә, бай, мул тормышта һәм бик тырыш, хезмәт сөюче алмачуар атлар яшәгән. Ялкау булмагач, алар әйбәт тормыш кичергәннәр. Кабан дуңгызлары хәерче илдә яшәгәннәр. Билгеле инде, кабан дуңгызлары алмачуарлар илендәге байлыкка кызыкканнар.

Әшәкелек эшләү, башкаларга начарлык кылу җиңел бит ул. Тик күпләр ул начарлыкның кире үзләренә кайтасын гына белеп бетермиләр. Безнең әлеге явыз алмачуар да моны аңламаган, әлбәттә. Ул бары бер уй-теләк белән генә янган, ничек тә булса Хан тәхетенә утырырга.

Әйдәгез, бу явыз һәм кабәхәт алмачуарга кушамат тагыйк әле. Алмачуарларның һәммәсе дә андый комсыз булмаган бит. Бутамыйк бүтәннәр белән диюем. Аның кушаматы Галишаһ булсын ди. Галишаһ алаша...

Менә шул Галишаһ кушаматлы алмачуар ат кабан дуңгызлары янына киткән. Һәм әйткән: «Әгәр дә соңыннан мине алмачуарлар иленә хан итеп куйсагыз, алмачуарлар биләмәсен басып алырга ярдәм итәм!» – дигән. Әнә шул рәвешле Галишаһ алмачуар үз туганнарын дошманнарга сатарга карар кылган.

Һай, ничек җир күтәрде икән ул мәхлүк алашаны!

Дуңгызлар Галишаһның бу тәкъдимен бик шатланып кабул иткәннәр инде, әлбәттә. Югыйсә, алмачуарны болай гына җиңә алмаслары көн кебек ачык бит инде. Ә Галишаһ үзе теләп туганнарын сатарга әзер тора.

(Дәвамы бар.)

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Резеда ЗӘЙНИ

Әллә кемнәр

Бүген балалар бакчасы эшләми. Ә Аязның әнисенә дә, әтисенә дә эшкә барырга кирәк. Әбиләренең дә авылга кайтып киткән чагы шул. Аптырагач, әнисе улын үзе белән эшенә – театрга алып барырга булды.

Бирегә беренче тапкыр килүе түгел түгелен, әмма һәр очракта да театр малайга матур да, серле дә дөнья булып күренә. Сәхнә артлары, бик күп урындыклар тезелеп киткән заллар, озын, буталчык коридорлар буйлап сәгатьләр буе йөрергә әзер ул. Тик бу юлы репетиция вакытында әнисен көткән араны үзенчә уздырырга туры килмәде. Театрга тагын бер малай килгән икән. Исеме сәер генә – Эдгар. Көне буе шуның белән икәүләп чабып йөрделәр. Аргач, Эдгарның әнисе янына менеп, сәхнәгә ут көйләвен карап тордылар.

Өйгә кайткач та, Аязның телендә театр гына булды. Сәхнәдәге абый-апаларның өстәл тирәли йөгерешеп йөрүләрен, әйткәләшүләрен, аннан елауларын хәтеренә төшерде. Боларның чын түгел, юри генә, уйнап кына булуын белә инде ул. Әнисенә яңа дусты турында да сөйләде малай. Аннан:

– Әни, әйт әле, Эдгар гел русча гына сөйләште, әллә татарча белми микән? – дип сорады.

– Белми шул, улым.

– Ә-ә, алайса ул рус малае инде, аңладым, – дип, үзенчә белдеклеләнеп нәтиҗә ясап куйды Аяз.

Әнисе:

– Юк, нишләп рус булсын, ул да синең кебек үк татар. Әнисе Марианна апаң да татар бит, – дигәч, малай тагын уйга калды.

Бераздан:

– Ә Марианна апа үзе татарча сөйләшәдер бит? – дип сорап куйды.


– Кем белгән инде аны, бәлкем сөйләшәдер дә. Тик минем ишеткәнем генә юк, – дип уфтангандай итте шунда әнисе.

Төшенеп җитә алмады әле Аяз. Ничек шулай булып чыга инде? Үзләренең исемнәре дә сәер, үзләре татарча да белми. Җитмәсә, әнисе аларны татарлар дип атады. Юк, татарлар түгел алар! Әллә руслармы? Алай булырга да охшамаган. Тик кемнәр соң, кемнәр? «Татар да, рус та булмаган әллә кемнәр генә инде шунда, әллә кемнәр генә...» – дип, үзалдына сөйләнеп куйды Аяз.



Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ





Ләбиб Лерон

Сугыш чукмары һәм тыныч малай

Рәссам
Фәрит Муллахмәт
Шалтмылтфильм



Матур, ямьле җәйләр үткәч,
Кергәч алтын көзләргә,
Җайлап кына сөйлим әле
Бер әкият сезләргә.

Коры җиргә, ипләп-сипләп,
Судан күпер салганда,
Яшәгән, ди ике малай
Кичә-бүген заманда.



Берсе – сугыш чукмары, ди.
Берсе – тыныч малай, ди.
Беренчесе көчсезләрне
Егып кына сала, ди.



Нәниләрнең тәм-томнарын
Тартып кына ала, ди.
Кызларны да кыерсыткан
Менә шундый малай, ди.



Тыныч малай исә аннан
Эше-шөгыле белән
Аерылып торган, хәтта
Холык-фигыле белән!



Эшләгәндә ут уйнаткан,
Матур итеп уйнаган.
Җитезлектә-өлгерлектә
Бер дә кимен куймаган.



Рәнҗетмәгән нәниләрне,
Кызларга да тимәгән.
Сугыш чукмары шикелле:
«Сез – мокытлар!» – димәгән...



Беркөн шул малай янына
Килгән сугыш чукмары.
Күз алдына китергән ул
Ничек шәпләп тукмарын...



Бәйләнүен бәйләнгән ул,
Орынуын орынган...
Ник сугыша башлавына
Үкенгәндер соңыннан.



Тыныч малай аны җирдән
Күтәргән, ди, нык итеп.
Сизми калган теге малай
Утырганын лып итеп!



Ишеткән ул: – Без тынычта
Аттан артык эшлибез...
Бел, син шуны: «Без – сугышта
Юлбарыстан көчлебез!»



Тыныч малай шулай дигән –
Тукай абыйча әйткән.
Теге малай аңлагандыр,
Син дә аңладың микән?!



Канатлы талант



Ида Вайнер талантлы шәхесләр гаиләсендә туган. Аның әтисе дә (Борис Вайнер), әнисе дә (Наилә Ахунова) – язучылар. Бәхет бер килсә килә бит ул: Иданың хәтта әбисе белән бабасы да язучылар! Гөлшәһидә апа белән Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов.

Ида – үзе дә бик сәләтле кыз. Матур-матур рәсемнәр ясый (кайберләренең «Салават күпере»ндә дә дөнья күргәне бар). Бу сәләт аңа бабасыннан йоккан, ахрысы. Гариф ага Ахунов та искиткеч матур рәсем-картиналар ясый иде.

Ида хәзер дәү кыз инде. Чит илдә белем ала. Рәсем ясавын һаман да дәвам итә. Әлеге сурәтләрне исә Ида мәктәптә укыган елларында ясаган.




Рәссам кыз сөекле бабасы янында. 1994, июль.



Дачада



Дәрес



– Ашыйсы бар, йомыш-фәлән...
Уйлыйсы, баш ватасы... –
Хәл итәсе мәсьәлә күп!
...Ә син җылап ятасың.

(Казан)





– Коткару җайланмасын
Кулымнан ычкындырмыйм.
Суга ялгыш төшүдән
Шуңа мин куркып тормыйм.

(Казан)





– Бик җайлап кына утырып,
Белеп-җайлап үз эшен,
Юктыр әле минем кебек
Гармун уйнаган кеше!


(Казан)





– Мәчебезнең колаклары
Шомырайды куркудан:
Тычкан-мазар тимәсен, дип
Мәче саклап утырам!

(Теләче, Балыклы)





– Мин булышмасам, баянда
Уйный да белмисең бит...
Шәп гармунчы итәм сине,
Әтием, телисеңме?

(Казан)





Имант Зиедонис,

латыш язучысы

Зәңгәр экият

Зәп-зәңгәр ат борчак эчендә!

Зәңгәр ат борчак эчендә!!!

Мин аны кичә күрдем. Ул борчакның зәңгәр чәчәкләрен чәйни иде.

Мин беләм: ни өчен ул ат зәңгәр икәнен.

Җир йөзендәге барлык атлар – каралары, турылары, колалары, чуарлары... – барысы бергә җыйгалганнар да:

– Әгәр машиналар җиңсә, без бөтенебез дә һәлак булачакбыз. Әйдәгез, болай эшлик: бер ат мәңгелек булсын! – дигәннәр.

Шулай дигәннәр дә алар мәңгелек ат зәңгәр булырга тиеш дигән бердәм фикергә килгәннәр.

Зәңгәр төс – хыял һәм өмет төсе.

Ниһаять, мәңгелек атка зәңгәр канатлар биргәннәр һәм аны Зәңгәр Өмет Аты дип атаганнар.

Барлык Атларның Гомуми Җыенында Зәңгәр Атның һәрчак ялгыз булырга тиешлеген искәрткәннәр. Беләбез ич, кеше дә ялгыз чакта гына моңлана, хыяллана, нәрсәгәдер өметләнә, нидер көтә...

Зәңгәр Ат ямансулап куйган. Әмма аңа шундук юату сүзләре тапканнар: ямансулык та зәңгәр төстә, ул сиңа бик килешә, дигәннәр.

– Син – Хыял Аты, – дигәннәр аңа. – Син без ни ашасак, шуны ашый, без ни эчсәк, шуны эчә аласың. Ләкин ул чакта син төсеңне җуячаксың һәм һәлак булачаксың. Син – Хыял Аты. Син бары тик күгәрчен күзе чәчәген генә чәйнәргә тиешсең. Зәңгәр чәчәкләр – синең ипиең. Су эчәсең килсә, зәңгәр таулар артындагы зәңгәр нарат урманыннан өч зәңгәр зирек агачын эзләп тап. Шунда зәңгәр чишмә очратырсың.

Анда өч зәңгәр яшен зәңгәр кылычлары белән куян куып йөрер.

Анда өч зәңгәр болыт мичкә эчендә тирән йокыга талган булыр.

Анда... Кыскасы, үзең карарсың шунда.

Онытма: син зәңгәр чиксезлектә яшәргә тиеш. Бары тик эңгер-меңгер чакта гына, бары тик зәңгәр иртәдә генә, бары тик кичке томан вакытында гына син кешеләр янына килә аласың...

Барлык Атларның Гомуми Җыенында шулай дигәннәр Зәңгәр Атка.

Иртә язда, миләш чыпчыклары кайткач, урманда умырзаялар чәчәк аткач, карагыз әле: Зәңгәр Ат эзләре күренмәсме?

Җәйләрен кырга чыгыгыз: анда җитен чәчәк атканын, Зәңгәр Ат уйнаклап чапканын шәйләрсез.


Кышларын зәңгәр эңгер-меңгердә чыршылардан төшкән зәңгәр күләгәләргә сокланып карагыз. Шулчакта Зәңгәр Ат зәңгәр күләгәләрне ялаганын күрерсез.

Кем дә кем Зәңгәр Атка атланып йөри, ул бөтен дөньяны зәңгәр итеп күрә. Аңа шомыртлар да, куяннар да, хәтта саңгырау гөмбәләр дә зәп-зәңгәр булып күренер.

Зәңгәр Ат – зәңгәр могҗиза. Зәңгәр Атка атланып йөргәннәр зәңгәр могҗизалар гына күрә. Дөрес, Зәңгәр Ат үз янына беркемне дә якын китерми. Әлбәттә, кайбер шагыйрьләрдән башкаларны. Хәер, әгәр сезнең зәңгәр солыгыз бар икән, ул чакта Зәңгәр Ат сезне дә атландырып йөртәчәк...

Сезнең бер уч зәңгәр солыгыз бармы?

Урысчадан **Ләбиб ЛЕРОН** тәрҗемәсе.





Айдар – Кыз. Ә син?..

Мин – Сукояр. Юк ла инде, болытка утырып су сибеп тормыйм. Дус кызым Ләйсән – Игезәк. Юк, аның да игезәк сыңары юк, әти-әнисенә бер бала. Илдар – Үгезбозау. Айдар – Кыз. Юк, юк, Айдар үзе – малай. Кыз йолдызлыгында туган гына ул. Туган айларыбыз шундый безнең. Ә син үзеңнең нинди айда туганыңны беләсеңме соң? Кем син, Балыкмы, Кысламы? Йә-йә, үпкәләмә инде. Үртәүем түгел, сорыйм гына бит. Менә, әйтик, Ләбиб абыең Лерон – Чаян. Ә Зиннур абыең Хөснияр – Кысла. Алар моңа бер дә үпкәләмиләр. Йолдызнамәләре шулай булгач, ник үпкәләсеннәр ди. Ишеткәнең бардыр бит, һәр айның үз йолдызлыгы була.

Январь – Кәҗәмөгез, февраль – Сукояр, март – Балык, апрель – Кучкар, май – Үгезбозау, июнь – Игезәк, июль – Кысла, август – Арыслан, сентябрь – Кыз, октябрь – Үлчәү, ноябрь – Чаян, декабрь – Укчы.

Инде әти-әниеңнең, туганнарыңның, дусларыңның кем икәнлекләре белән кызыксынып кара.

Беләсеңме, әле елларның да шундый сәер исемнәре бар. Хәер, еллар турында без киләсе сәхифәбездә сөйләшербез. Ә әлегә шуны гына әйтәм.

Римлылар башта елны дүрт айга бүлгәннәр. Аннан соң тагын алтыны өстәгәннәр. Ума Помпилий тагын ике айны кушып куйган да, шуннан безгә мәгълүм ел барлыкка килгән.

Илсөяр Иксанова

Ай яктысы

Кояш билгеле бер вакытта җирнең бер ягын яктырткан кебек, айның да бер ягын гына яктырта. Ай җир тирәли әйләнә. Һәм без айның якты ягын гына күрәбез. Айның төрле формаларга керүенең сәбәбе дә менә шул. Айның караңгы ягын без күрмибез. Тик ул бар.



Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА



Куык, салам һәм чабата

БЕРТУГАН ГРИММНАР

(А.Толстой эшкәртүендә)



Яшәгән, ди, куык, салам һәм чабата. Беркөнне киткәннәр болар урманга — утын кисәргә. Бер инеш буена килеп җиткәннәр дә аргы якка ничек чыгарга белмичә торалар икән.

Чабата куыкка әйтә икән:

– Куык, әйдә, сиңа утырыйк та йөзеп чыгыйк!

– Юк, юк, чабата! Әйдә, без болай итик: салам ярдан ярга сузылсын, ә без икәү аның аша чыгыйк.

Салам бер ярдан икенче ярга сузылган. Чабата салам буйлап киткән. Салам кинәт сынган да чабата суга мәтәлгән.

Куык көләргә тотынган. Шулай чыдый алмыйча көлә торгач, куык шартлаган, ди...

Урысчадан Ләбиб ЛЕРОН тәрҗемә кылды.

Башваткычлар



8 аерма тап.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Бу рәсемдә нинди сүз яшерелгән?

Сәләват күпере

10(151) — 2002

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Лилия ЗОЛОНДИНОВА рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 03.10.2002 ел.
Басарга кул куелды 03.10.2002 ел.
Кәгазь форматы 60x100 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 11631 данә. Заказ Б-568.
Бәясе килешү буенча.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб Лерон

Татар баласы

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә:
Нинди гүзәл татар кызы! –
Күз тимәсен үзенә.

Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә:
Нинди матур татар улы! –
Күз тимәсен үзенә.

Үзе тыйнак, үзе горур,
Хак сүз булыр әйткәне.
Яратыр газиз Ватанны,
Сөяр әткәй-әнкәйне!

Дәү булгач та, шулай калыр –
Татар баласы булып.
Әйтерләр:
– Татар кызы бу!
Диярләр:
– Татар улы!

